| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| _13.12.2018___ | г.Лениногорск | № _172_ |

«Җир салымы турында» 2015 елның 27 октябрендәге 18 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карарына өстәмәләр кертү хакында (18.11.2015 № 39, 2016 елның 14 июлендәге 67 номерлы, 2017 елның 30 маендагы 102 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 маддәсенең 2 нче пункты нигезендә, Лениногорск шәһәр Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2015 елның 27 октябрендәге 18 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карарына (18.11.2015 № 39, 2016 елның 14 июлендәге 67 номерлы, 2017 елның 30 маендагы 102 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4 абзац өстәргә:

«- 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны салым түләүдән азат итеп, ташлама бирергә.»;

түбәндәге эчтәлектәге 6.1 пунктны өстәргә:

«6.1 Салым түләүчеләр - салым ташламаларына хокуклы физик затлар, шул исәптән салым һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым тотып калу рәвешендә салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым органында булмаган очракта, шул исәптән салым түләүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә тапшырылмаган очракта, салым органы салым ташламасы бирү турында гаризада күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы белешмәләрне шул белешмәләре булган органнардан, оешмалардан, вазыйфаи затлардан соратып ала.

Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләр бирү турында салым органы гаризасын алган зат аны алган көннән алып җиде көн дәвамында башкара яисә шул ук вакытта сорауны үтәмәү сәбәпләре турында салым органына хәбәр итә.

Салым органы күрсәтелгән хәбәрне алган көннән соң өч көн эчендә салым түләүчегә әлеге салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләр соравы буенча һәм салым түләүченең раслаучы документларны салым органына тапшыруның кирәклеге турында хәбәр итәргә тиеш.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор-«Лениногорские вести»газетасында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында - http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры

Р.Г. Хөсәенов